# Г.ГОБӘЙНЕҢ “ЛӘЙСӘН ЯҢГЫР” ПОВЕСТЕНДА СУРӘТЛӘНГӘН ДӨНЬЯ

*Гайнуллина Г.Р., Казань, КФУ, канд. филол. наук, доцент*

**Аннотация:** Статья посвящана анализу изображенного мира, художественных приемов в татарской детской прозе 1950-60-х г.г. Объектом изучения является ранее не исследованное произведение Г.Губая “Летний дождь”.

**Ключевые слова:** детская проза, повествование, художественные приемы.

**Abstract:** The article is dedicated to the analysis of the given world and the artistic techniques in the Tatar children's prose in 1950-60-ies. The object under study is a piece of work "Summer rain" by G.Gubai that hasn't been analyzed before.

**Key words:** children's prose, naarration, artistic techniques.

XX гасыр балалар әдәбиятының үзенчәлекләрен һәм үсеш тенденцияләрен махсус гыйльми хезмәтләрендә өйрәнгән әдәбият галиме Л.Минһаҗева “Бөек Ватан сугышынан соңгы елларда балалар прозасы берничә юнәлештә үсә [3:180], – дип билгели. Мәгълүм булганча, сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1945-1956) халыктагы җиңү шатлыгын, тормышның үзгәрәчәгенә, хакыйкатьнең идеологик басымны җиңеп чыгачагына ышаныч җырлаудан репрессияләрнең яңа дулкыны, цензураның көчүе сәбәпле торгынлыкка таба үзгәрә бара [2:133].

Гариф Гобәйнең балаларга адресланган прозасында үз чорының тирән проблемаларын, фаҗигасен күңеленән уздыручы бала-герой алга куела. Әдипнең “Замана балалары” (1949), “Маратның язмышы” (1956) әсәрләрендә күтәрелгән ил язмышы, балалар язмышы белән бәйле фикерләр “Ләйсән яңгыр” (1957-1960) повестенда да дәвам иттерелә. Максатыбыз – бүгенге көнгәчә игътибар үзәгеннән читтә калып килгән әлеге повестька бәя-анализ бирү.

“Ләйсән яңгыр” повестеның тышкы композициясе ике кисәкне үз эченә ала. Әсәрнең беренче кисәгендә җитеп килүче кыз Гүзәл күңелендәге акыл һәм йөрәк-хис, уянып килүче кеше омтылышлары бәреләшә. Һәр кисәкнең ахыргы бүлекчәсе – авторның укучыга мөрәҗәгате, аңлатмасы. Әсәрнең лейтмотивы – ялганга корылган чынбарлыкта көн күрүче кеше фаҗигасе. Автор гаилә-

җәмгыять чылбырын, аның шәхес формалашуга йогынтысын дәвер сулышына бәйле төстә трагик пафос белән сурәтли.

Беренче кисәк унбер бүлекчәдән гыйбарәт. “Гөлчәһрә апа, мин дә ялганладым...” исемле беренче бүлекчәдә ялганга корылган гаиләдә көн күрүче нәни Гүзәлнең әнисе кушканга Габсаттар бабайга әтисен өйдә юк дип алдавы хикәя ителә. Кызның күңелендә туган беренче каршылык *эчке сөйләм алымы* белән болай сурәтләнә: *“Ялганлады бит! Әнисе үзе кушты. Башка вакыт печтик кенә ялганласа да, тирги иде, бу юлы үзе кушты...”* [1:31]. Гүзәл кылган гамәлен шундук төзәтергә ашыга, ләкин әнисе туктата: *“Әти-әни сүзеннән чыгарга ярамый дип өйрәтмәделәрмени мәктәбегездә?”*[1:316]. Баланың җавабы кыска, анык: *“Ялганларга ярамый дип өйрәттеләр”*[1:316]. Кыз Габсаттар бабасына карата кылган ялгышын төзәтергә дип, автомат-телефонга йөгерә, әмма, ни хәл итәсең, биредә ул икенче гаделсезлек белән очраша: сөйләшергә дип телефонга акча салуга трубканы әдәпсез елдам малай тартып ала: *“Гүзәлнең дәфтәргә дип саклаган тагын бер унбиш тиене бар иде, ләкин ул көтеп тормады: дәрескә соңга кала” ”*[1:316].

Автор әсәрнең буеннан-буена урынны алыштырып тора. Укытучы Гөлчәһрә апасы бер баланың ялганын тотып оялту вакыйгасын сөйләгәннән соң, Гүзәл үзе белән булган вакыйганы мисал итеп китерә: *“Гөлчәһрә апа, мин дә ялганладым... Габсаттар бабайга ... Әти кушты, әни дә...” ”*[1:317]. Тәрбиядә сүз белән гамәл берлеге дип кузгатылган проблема бала теле белән әйттерелә, көчәйтелә. Кечкенә Гүзәл иң якын, ихтирам иткән кешеләренең ялганына юлыга.

Бала күңелендә урнашкан кагыйдәләрнең күпчелеге өлкәннәрнең үз-үзен тотышына бәйле икәнлеге кайта-кайта ассызыклана. Автор хикәяләү барышында *композицион кабатлау алымын* куллана. Гүзәл әнисе кушуы буенча икенче тапкыр ялганлаганда инде вөҗдан газабы кичерми, өченче тапкып әнисе кушканчы алдап өлгерә, ләкин әти дигән кешенең ялган өчен кызны бүләкләве өчен уңайсызлана һәм нәфрәтләнә дә. Ләкин Гүзәлне ялган чоңгылы бөтереп

алып, әдәпсезлек, әхлаксызлык, җинаятьләр дөньясына алып кереп китәчәгенә укучы әлегә әзер түгел.

Автор балалар прозасы кысаларында иҗтимагый проблеманы атый, чор фаҗигасен тасвирлый. Г.Гобәй шәхес культы дәвере проблемасы – идеология ялганы турындагы мәсьәләне кузгата. Гүзәл мәктәпкә аяк басасы елны "ят кешеләр" әтисен тимер рәшәткәле, кызыл билле кара машинага утыртып алып китәләр, өйдәге китап шкафын, әтиләренең язу-сызуларын тар-мар итәләр.

Билгеле булганча, "сугыш елларында беркадәр басылып торган репрессия сугыштан соң яңадан куәт ала. Әсирлектә булучылар да, саксызлык белән үз фикерен әйтеп ташлаучылар да, гомумән идеология ялганын күрә алган акыл ияләре, күршесе ачудан гына яла ягып тиешле оешмага хәбәр иткән теләсә нинди очраклы кешеләр меңәрләп-меңәрләп төрмәгә озатыла башлый. 1938 елгы фаҗига кабат әйләнеп кайта. Ләкин 50 елларның ул еллардан шактый аермасы да бар. Төрмәләр, лагерьлар халыкка хакыйкатьне ачу мәктәпләренә әвереләләр. Үзләренең каршылыклы уйлары белән аларга Европа илләрендәге тормышын күреп кайткан сугышчылар да өстәлә. Рәсми хакыйкать янында яшерен рәвештә кешеләр аңында чын хакыйкать яши башлый. Бу хәл Сталин үлгәнче үк башлана "[4:52]. Повесть 1957-1960 елларда – Сталинның шәхес культы фаш ителә башлаган дәвердә иҗат ителә. Гүзәлнең кичерешләре аша автор нахак бәла ягып төрмәгә утыртылганнар проблемасын атый: *"Гүзәл исә гаиләнең нинди дер бәхетсезлеккә дучар булганлыгын аңлый иде"* [1:316].

Бу урында ул дәвернең меңләгән балалары өчен уртак проблема – өзелгән балачак проблемасы кузгатыла: *"Ул хәзер йорттан чыгып йөрмәс булды. Балаларның уйнап йөргәннәрен капка ярыгыннан яки тәрәзәдән генә карап тора иде"* [1:319]. Сугыштан кайткан хезмәт кешесен ришвәт алуда, шпионлык итүдә – фин сугышы көннәрендә Төркия кешесенә хәрби серне чишүдә гаепләп юк итү фаҗигасен автор персонажлар теле белән калкыта: *"... Гаепле иде микән әле ул? Трамвай юлы себерүдән башлады бит. Күз ачкысыз буран, ә моның өстендә юкарып беткән кыска пиджак, тар каеш, кырык ямаулы ботинка,*

*киндер биялэй... Үзе шуңар да канәгать, мескенкәй, эштән туктауга ликбезга чаба... Унбиш елга бит.. ”*[1:319-320].

Гаиләне җимерүче, бәхетсезлек китерүче – үзен гаилә башлыгы Сабирҗан Дәүләтъяровның “фронтовик дусты Хәррәмов” дип тәкъдим иткән икейөзле алыпсатар. “Ялгыш хөкем бу”, “идеал ул безнең Дәүләтъяров” ”[1:320] дип ялганлап гаилә эченә үтеп кереп, Асиянең тормышын җимергән бу кеше, асылда, аның иренең кан дошманы. Сәүдә министрлыгының өлкән ревизоры Сабирҗан Дәүләтъяров хөкүмәтне талап ятуда гаепләп, Госман Хәррәмовны судка бирә. Йортсыз-нисез үз малаена да битараф Хәррәмовның авыру хатынын ташлап, Асияне кол итү максатыннан, аның күңеленә үтеп керүе, алдап-йолдап өйләнүе, аның йорт-җирен сатуы, балаларны үз исеменә күчерүе дә үч алу максатыннан: *“Төрмәдән кайткач, барыбер башыңа җитәм мин синең. Инде мин кайтуга үлеп котылган булсаң, хатын, бала-чагаларыңнан алам үчемне”* [1:324].

Автор, шул рәвешле, кешеләр арасындагы дошманлыкның нигезен атый – ялган. Ялган кешеләрдә курку хисе, буйсыну ихтыяҗы барлыкка китерә, ди ул. Асиянең кол сыйфатында гомер кичерүгә риза булып торуы чиста күңелле кызда нәфрәт уята. Шул урында автор буйсындырып куркытып яшәүдән артыкны булдыра алмаган сыра сатучы дүрт класс белемле Госман Хәррамов психологиясен горур, якты күңелле, гомер буе гыйлем эстәгән Сабирҗан Дәүләтъяров хакыйкате белән янәшә куя. Мәктәп, гаилә темасына төреп, Г.Гобәй ялганга корылган чынбарлыкның тискәре йогынтысы проблемасын күтәрә, якты күңелле Гүзәлнең бәхетсезлегенең нигезли. Икенче бүлекчәдә Гүзәлне иптәшләре, укытучысы алдында сыра кибетендәге өстәлләрне җыештырырга мәҗбүр иткән ата тиешле кешенең кызны сату-алу, ялган эшенә күнектерүе хикәяләнә. “Алдашкан өчен, иптәшләрен алдаган өчен” Хәррәмов дәфтәр саткан кызга табышны тулаем биреп алдый.

Ни карышып та, ямьсез сүз ишетүдән артыкка ирешмәгән ана исә кызын үгетли: *“Карышма, бәлкем җае чыгар әле... Тыңларга туры килә”* [1:332], – ди. Кыз исә карышуның ярдәм итмәячәген аңлый: *“Гүзәл, үз намусына каршы*

*барып булса да, күнде. Һәм ул күнегүләрне торган саен әйбәтрәк, кыюрак башкарып чыкты"*[1:332]. Кыз Хәррәмовның бөтен боерыгын җиренә җиткереп башкара, "иптәш кызларына күренмәс өчен ышыкланып", шикәр сатып йөри. Милиционер белән булган вакыйга аны хәйран калдыра. Аннан шикләнеп килгән милиционердан кызны Хәррәмов коткара, гаделлек сакчысының игътибарын җәлеп итәр өчен үзен таладылар, дип кычкыра. Бу хакта белгәннән соң *"Гүзәл шаклар катты. Хәррәмовның бу тапкырлыгы аңа хәтта ошады"* [1:334]. Хәррәмов кыздан *"культуралы совет сәүдәгәре"* [1:335] әвәли. Икеле капчыгына әйләнеп, класстан класска күчә алмаган баланың киләчәге өчен "укыган халык – чукынган халык" дип акланучы ата тиешле бу адәм шулай җаваплы. Нәтиҗәдә, Гүзәл өчен алдау, ялган гадәтигә әйләнә, сыра кибетендә прилавкада торырга да, кеше хакын хакламаска да тиз күнегә кыз. Кызының ялган юлына кереп китүеннән йөзләре җыерчыкланып, гәүдәсе тупасланып киткән ана "колларча тугры хезмәт итүен" дәвам итә, "үзенең җыры җырланып беткән саный", Гүзәл зарланып елаганда "зинһар, сабыр итә күр", дип үгетли. Аналы-кызлы кол булып, сабыр итеп яшәгән арада Хәррәмов Дәүләтъяровның төрмәдән чыгуына әзерләнә: гаилә фотосын төрмәгә юллый.

Автор коллык фәлсәфәсенең нигезен курку, ялганга, гаделсезлеккә риза булып яшәү нәтиҗәсе итеп дәлилли. Кайчандыр өлкәннәр ялганлаганга хәтере калган Гүзәл "кыяр кебек бөрешеп беткән әбине" "рәхәтләнеп талый". Хәррәмовларның ялганга корылган чынбарлыгы янәшәсендә Сабирҗанның акыл, намуска нигезләнгән яшәеше кабатланып тасвир ителә. Бала-герой исеменнән хакыйкать җиткерелә, әсәр дәвамында кабатлана да: *"Нигә шундый булдың соң син әтием, безнең өчен яхшы, хөкүмәт өчен әшәке булдың?"* [1:347]. Потенциаль эчтәлектә автор нахакка гаепләнгән буын фаҗигасенең сәбәбен атый – ялганга корылган чынбарлыкка риза булып, сабыр итеп яшәү. Бу өлештә алмагач чәчәге, скрипка тавышы, җыр *әдәби детальләре психологизмны* көчәйтеп килә. Алтынчы бүлекчәдә курку хисе, коллык белән

килешү китереп чыгарган алдагы нәтиҗә атала – гаепле икәненеңне белеп, берөзлексез аклануга, башка берәүнең сине яклавына мохтаҗ булу проблемасы.

Атаклы карак, колониядән кайткан Җиһангир – Госман Хәррәмовның ташландык малае (Габсаттар абыйга шалтыратып торган кызның кулыннан телефонын тартып алып дорфа сөйләшкән Бакыр чәч) Гүзәлне тулысынча юлдан яздыра. Үсмер кыз Гүзәлнең сөю-сөелүләр дәрьясына кереп китүе машиналы егет Альфред һәм ташчы белән бәйле. Ялганга нигезләнгән чынбарлык чоңгылы, авырлыклардан могҗиза белән качып котылу кызны һәрдаим үзенә тартып тора, бу – куркуның алдагы нәтиҗәсе. Кыз кылган ялгышларны төзәтү, әнисенә ихтирамлы булып, язмышны үз сукмагына кертеп җибәрәсе урынга сату-алу эшенә чума. Язмышы аңа кул да суза кебек, ташчы егет Таһирҗан аңа үзгәрергә ярдәм итәргә әзер, Гүзәл үзе каршы түгел. Тик Таһир хыянәтеннән күңеле кителгән Гүзәл үзе дә сизмичә карак Альфред дөньясына эләгә, "тутый кошка" әверелә, алар белән бергә җинаятьләр кыла.

Икенче кисәк беренчесенең дәвамы, автор аңлатуына караганда, колония начальнигы Фәезханова ханым белән очрашу нәтиҗәсендә языла. Унсигез бүлекчәдән торган бу өлеш шулай ук авторның аңлатмасы белән тәмам ителә. Пейзаж детале белән башланып килгән беренче бүлекчәдә Гүзәлнең алдагы язмышы хикәя ителә. Биредә табигать сурәте сюжетка керү вазифасын башкара: *"Идел буе. Көз кергән инде, сентябрь урталары; ә биек яр читен каплап урман бирешми әле, аңа тик урыны-урыны белән генә чал кергән. Ул, яшел башын чак иеп, юмарт кояш нурлары астында тын гына оеп утыра. Табигать назлысы – Идел үзе дә тын. Дулкын түгел, бер шадра да юк Идел өстендә"* [1:395]. Юлдан язу алдында торган Гүзәл, качып котылырмын дигән ышаныч белән читтә йөргәннән соң, кайтып, һөнәр мәктәбенә укырга килә. Биредә автор чор фаҗигасен сугыш фаҗигасе белән бәйле тамгалап куя: *"Биредә укытучыларга хәтле бүтән иде. Күбесе детдомнардан килгән, сугыш сәбәпле ятим калып, дөньяның әчесен-төчесен туып үскән, әти-әни иркәләвен, әти-әни назларын күрми үскән балалар иде"* [1:400]. Сагыш, хәсрәтле чынбарлыкта тәрбияләнгән, коллык психологиясенең бөтен нечкәлекләрен үзләштергән кызга язмыш

сынаулар әзерли. Һөнәр мәктәбендә аны Җиһангир белән очрашу көтә булып чыга, җинаятьче Хәррәмов малае кол Асия кызын эзәрлекләүдән тәм табарга гына тора. Куркуның тагын бер нәтиҗәсе – гаепле икәнеңне сизеп, башкаларның синең гаепне фаш итүләреннән качып яшәү. Кайчандыр әнисе Хәррәмовка ышанган кебек, Җиһангир төзәлер, яхшылыкның кадерен белер, дип инанган беркатлы Гүзәл тагын җинаять кыла. Шул урында язмыш төзәлү-үзгәрү өчен Гүзәлгә кайчандыр үзе дә өч тапкыр төрмәдә утырган Газизә апаны җибәрә. Игелекле директор туган көнендә тәрәзәсенә таш аткан кызны җәберләми, киресенчә, кызгана, хезмәт тәрбиясе бирә, үз көче белән тапканның рәхәтен татырга өйрәтә: Автор куркуны җиңүнең бер һәм бердәнбер юлын күрсәтә – үзеңнең гамәлеңне намус белән җиренә җиткереп башкару, кешеләрдә ышаныч яулау. Ләкин автор Гүзәлдәге куркуның беркайчан җуелмаячагын искәртә. Гүзәл – шәхес культы заманасы корбаны, нинди дер карарга килер алдыннан аны гаиләсенең кара сакалы ихтыярый-мәҗбүри туктап калырга, буйсынырга мәҗбүр итә.

Г.Гобәй куркуны җиңүнең юлы – намуслы гамәл, яратып, кичерә белеп яшәү, горур булу, коллык юлы белән килешмәү дип һәр персонаж язмышында кабатлый. Гүзәл үз әтисе турында кычкырып әйтергә кыюлык таба, Таһир әхлаксызлык юлына баскан Гүзәлне кичерә, Мөршидә Җиһангирны гафу итә, Асия Хәррәмовка янәдән кайтып, кол булып яши башлаганнан соң, Госман хөкем ителә. Сабирҗан гаиләсен эзләп таба. Автор әсәрнең дәвамын язарга мәҗбүр иткән Фәезханованың Гүзәл үзе икәнлеген әйтә.

Автор хикәяләү барышында әдәби алымнарны уңышлы куллана. Чор фаҗигасен коллык психологиясе белән бәйләп аңлата алу Г.Гобәйнең язучы буларак әдәбият тарихындагы урынын билгели.

ӘДӘБИЯТ

1. Гобәй Г. Ләйсән яңгыр / Сайланма әсәрләр. Повестьлар. – Казан, 1969. – Б.315-511.

2. Заһидуллина Д.Ф. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М. Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т.2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

3. Минһаҗева Л.И. XX гасыр татар балалар әдәбияты: үзенчәлекләре һәм үсеш тенденцияләре. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2011. – 312 б.

4. Яхин А.Г. Әдәбият. Татар урта гомуми белем мәкт. 11 с-фы өчен дәреслек-хрестоматия. – 2 басма. – Казан: Мәгариф, 2003. – 383 б.